ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление
№1 | 29 гыйнвар,2026 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегендә җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Башкарма карар бирә:

1. Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 9678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм 2026 нче елның 1 февраленнән 1 нче һәм 2 нче Кушымталар нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 31 гыйнвар «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында » №4 карарын гамәлдән чыкты дип таныргa.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында («Нократ ("Вятка")) бастырып чыгагрырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче: ____________ / В.В.Шрыков/

Татарстан  Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29гыйнвар 2026 ел , № 1
карарына
1 нче  кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге җирлекара күмү
урыннарында җирләү  буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы
вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 4452,21 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1160,20 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4066,33 |
| Барлыгы | 9678,63 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29 гыйнвар 2026 ел , № 1
карарына
2 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1381,27 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3197,37 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1183,58 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3916,42 |
| Барлыгы | 9678,63 |